**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422646, с. Большой Ошняк,
ул. Г.Тукая, дом 28а

**КАРАР**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ӘШНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422646, Олы Әшнәк,
Г.Тукай урамы, 28а нче йорт,

Тел.: (84361) 27738, факс: (84361) 27738, e-mail:Bosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 01 июне Олы Әшнәк авылы № 8

2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының салым чыгымнары исемлеген формалаштыру (төзү) һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $174^3$ маддәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге “Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләренең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында” 796 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге җирлеге Башкарма комитетының кушымта итеп бирелә торган салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен расларга.

2. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә 1 сентябрьгә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге җирлеге Башкарма комитетына хисап елындагы, хисап елына кадәрге ел өчен булган мәгълүматларны җибәрергә тәкъдим итәргә:

ташламалардан файдаланучы түләүчеләр саны турында;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге җирлеге Башкарма комитетының һәр салым чыгымы буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге җирлеге Башкарма комитеты бюджетының төшеп калган керемнәре суммалары турында.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28А йорт; Кече Әшнәк авылы, Красноармейская урамы, 32А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Башлыгы Р.А.Хөснетдинова

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының
2020 елның 01 июне 8 номерлы
карары белән расланды

2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының салым чыгымнары исемлеген формалаштыру (төзү) һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру
**Тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының салым чыгымнары исемлеген формалаштыру (төзү) һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының салым чыгымнарын бәяләүне уздыру кагыйдәләрен билгели (тәгаенли) (алга таба – Тәртип, муниципаль берәмлек).

2.Тәртиптә Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге "Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләренең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында" 796 номерлы карары белән расланган гомуми таләпләр белән билгеләнгән терминнар һәм төшенчәләр кулланыла (алга таба – Гомуми таләпләр).

3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар, муниципаль программаларның структур элементлары һәм (яисә) муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

4. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында муниципаль берәмлек башкарма комитеты:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзи (формалаштыра);

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләрен анализлауны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра.

## II. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеге муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан төзелә һәм агымдагы елның 1 июненә кадәр раслана.

6. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының расланган исемлеге муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

7. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына муниципаль берәмлекнең финанс хисап елына

һәм хисап елы алдындагы елга салым чыгымнарының фискаль сыйфатламалары турында мәгълүмат бирә.

8. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләүне уздыру максатларында муниципаль берәмлек башкарма комитеты ел саен, 1 августка кадәр, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә, муниципаль берәмлекнең тиешле салым чыгымнарын күздә тотучы норматив хокукый актларын, шул исәптән хисап елында һәм аннан алдагы елда гамәлдә булганнарын күрсәтеп, түләүчеләр категорияләре турында мәгълүматларны һәм әлеге Тәртипкә кушымтада каралган башка мәгълүматларны юллый.

9. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә кертелгән мәгълүматны үзгәртүне күздә тоткан норматив хокукый актлар кабул ителгән очракта, муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тиешле норматив хокукый акт үз көченә кергән көннән соң 10 эш көне эчендә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә тиешле үзгәрешләр кертә.

## III. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү тәртибе

10. Салым чыгымнарын бәяләү муниципаль берәмлек башкарма комитеты тарафыннан башкарыла һәм үз эченә ала:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары күләмнәрен бәяләүне;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне.

11. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү үз эченә ала:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатчанлыгын бәяләүне;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләүне.

12. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатчанлыгы критерийлары булып тора:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының муниципаль программаларның максатларына, муниципаль программаларның структур элементларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисади сәясәте максатларына туры килүе;

ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләрнең саны һәм биш еллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән сыйфатлана торган салым ташламаларына салым түләүчеләрнең ихтыяҗы булу.

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсенә генә булса да туры килмәгән очракта, муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына түләүчеләр өчен ташламаларны саклап калу (анықлау, бетерү) турында тәкъдимнәр тапшырырга кирәк.

13. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының нәтиҗәлелеге критерие буларак муниципаль программа максатларына яисә муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади сәясәте максатларына ирешүнең кимендә бер күрсәткече (индикаторы) яисә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары әһәмиятенә йогынты ясый торган башка күрсәткече (индикатор)

билгеләнә. Әлеге күрсәткеч (күрсәткечләр) хисап елында, хисап елына кадәрге елда, агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына билгеләнә.

Түләүчеләр өчен каралган ташламаларның муниципаль программа максатларына ирешү күрсәткеченең (индикаторның) һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисади сәясәте максатларына ирешү күрсәткечләренең (индикаторының) мәгънәсен үзгәртүгә керткән өлеше бәяләнергә тиеш, ул ташламаларны исәпкә алып күрсәтелгән күрсәткеч (индикатор) кыйммәте һәм ташламаларны исәпкә алмыйча күрсәтелгән күрсәткеч (индикатор) кыйммәте арасындагы аерма буларак исәпләнә.

14. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүне үз эченә ала.

15. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү максатында муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына ирешүнең һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларына кермәгән социаль-икътисади сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану нәтиҗәлелегенә һәм ташламаларны бирү нәтиҗәлелегенә чагыштырмача анализ ясала.

16. Чагыштырма анализ муниципаль берәмлек программасы максатларына ирешүнең һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларына кермәгән социаль-икътисади сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын кулланган очракта муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары күләмнәрен һәм бирелгән ташламаларның күләмнәрен чагыштыруны үз эченә ала (муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларына карамаган социаль-икътисади сәясәте максатларына ирешү күрсәткечләренең (индикаторның) үсешен исәпләп чыгару, муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларының салым чыгымнарының 1 сумына һәм шул ук күрсәткечкә (индикаторга) ирешү өчен муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарының 1 сумына альтернатив механизмнар кулланылган очракта).

Муниципаль берәмлек муниципаль программасы максатларына ирешүнең һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларына карамаган социаль-икътисади сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнары сыйфатында шул исәптән исәпкә алынырга мөмкин:

а) муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән ташламаларга хокуклы түләүчеләргә турыдан-туры финанс ярдәменең субсидияләр яисә башка рәвешләре;

б) ташламаларга хокукы булган түләүчеләрнең йөкләмәләре буенча муниципаль гарантияләр бирү;

в) ташламаларга хокуклы түләүчеләр эшчәнлеге өлкәсендә норматив җайга салуны һәм (яки) контроль-күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыру тәртибен камилләштерү.

17. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү 1 октябрьгә кадәр башкарыла һәм үз эченә ала:

- салым чыгымнарын бәяләүне уздыру өчен Күрсәткечләр исемлеге буенча мәгълүматны;

- салым чыгымнарының максатчан сыйфатламаларына ирешү (ирешмәү), муниципаль программа максатларына һәм (яисә) социаль-икътисади сәясәт юнәлешләренә (максатларына) ирешүгә салым чыгымының кертеме турында нәтиҗәләрне үз эченә алган язма аңлатмаларны;

- аларга ирешүнең тагы да нәтиҗәлерәк альтернатив механизмнары булу (булмау) турында тәкъдимнәрне;

- салым чыгымнарын саклау, аныклау (юк итү), яңа салым чыгымнарын билгеләү буенча тәкъдимнәрне.

18. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләре муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

Кушымта

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының салым чыгымнарын бәяләүне уздыру өчен күрсәткечләр исемлеге

| Күрсәткечнең аталышы | | Мәгълүматлар чыганагы |
|---|---|---|
| I. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының норматив һәм максатчан сыйфатламалары | | |
| 1. | Салым ташламаларын, алардан азат итүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган муниципаль берәмлекнең норматив хокукый акты | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 2. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр бирү шартлары | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 3. | Салым ташламалары, азат итү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 4. | Салым ташламалары, азат итү һәм салымнар буенча башка преференцияләр билгели торган муниципаль берәмлек норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 5. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән салым ташламаларына, азат итүгә һәм салымнар буенча башка преференцияләргә хокук бирә башлау датасы | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 6. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларының, азат итүләрнең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 7. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларының, азат итүләрнең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең гамәлдә булуын туктату датасы | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 8. | Салым ташламалары, азат итүләр һәм салымнар буенча башка преференцияләр аталышы | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 9. | Салым чыгымнарының максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаштыручы яисә техник ташламалар) | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 10. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, азат | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |

| | | |
|---|---|---|
| | итүләрне һәм салым түләүчеләр өчен башка преференцияләр бирү максаты | |
| 11. | Салым ташламалары, азат итү һәм муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән башка преференцияләр каралган салымнарның аталышлары | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 12. | Түләүчеләрнең аерым категорияләренә бирелгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм бүтән преференцияләрнең башка түләүчеләр белән чагыштырганда өстенлекләре үзенчәлекләрен билгели торган төре | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 13. | Салым ташламалары, азат итүләр һәм салымнар буенча башка преференцияләр бирелә торган салым ставкасы күләме | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 14. | Салым ташламалары, салымнар буенча азат итүләр һәм башка преференцияләр бирүгә бәйле рәвештә дәүләт программаларына карамаган муниципаль программаларның һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади сәясәтенең максатларына ирешү күрсәткече (индикаторы) | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| II. Салым чыгымының фискаль сыйфатламасы | | |
| 15. | Хисап елы өчен һәм хисап елына кадәр булган ел өчен муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары нигезендә салым түләүчеләр өчен салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр күләме (мең сумнарда) | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |
| 16. | Агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына салым түләүчеләр өчен бирелгән салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр күләмен бәяләү (мең сумнарда) | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |
| 17. | Салым ташламасыннан, азат итүдән һәм муниципаль берәмлекнең хокукый актларында билгеләнгән башка преференциядән (берәмлекләрдән) файдаланган салым түләүчеләр саны | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |
| 18. | Салым чыгымының нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләре | Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты |